

Әгәр кеше тезелергә уйласа, күпме кирәклеген тагын бер кат әйтеп китv кирәк микән! Шуна кvрә Лямбирь халкы гына тvгел, тирә-як авыллардан да «Сельхозтехника» микрорайонына, шәхси эшмәкәр Роберт Ринат улы Грошев кибетенә ашыга. Анда теләгән һәркем хужалыкта кирәкле товарларны сатып ала ала. Остәвенә, аларга бик әдәпле һәм тиз хезмәт кvрсәтәләр, барысын да кvрсәтеп кинәшләр дә бирәләр. Биредә менеджер Рамиль Бәсыйр улы Курмакаев кына тvгел, ә сатучыларнын да тозелеш материалларына кагылышлы зур белемнәре бар. Һәм Лямбирда даими рәвештә тозелеш баруын исәпкә алсак, клиентлар житәрлек. Халык бу кибетне «Безнен Леруа Мерлен» дип тә атап йортә.
Чират житте анда эшләvчеләр белән якыннан танышырга. Үз вакытында Рамиль Бәсыйр улы аграр институтны «зоотехния» белгечлеге буенча тәмамлаган. Әмма яшәешкә тормыш vз коррективларын кертә: ул сәvдә олкәсенә эшкә килә. Әлбәттә, биредә барысы да анын очен яналык була. Әмма vзе әйтvенчә, ана беренче коннәрдән vк тезелеш кирәк-ярагына ияләшергә остаз сыйфатында Ольга Валерьевна Даньшина ярдәм итә. Ул вакытта Рамиль Бәсыйр улы тозелеш материалларын да яхшы vзләштереп олгерә, чонки vз ишегалдындагы мунчаны ул vзе, vз куллары белән салган һәм мунча бик тә унышлы килеп чыккан. Сатучы Ольга Валерьевна Даньшинага килгәндә, ул кооператив институтын тәмамлаган, бухгалтер булып эшли башлаган, ләкин…
- Беләсезме, шундук диярлек монын минеке тvгеллеген анладым, - дип сойләде ул безнен корреспондентка. Тау-тау кәгазьләр, документлар... монда исә мин һәрвакыт хәрәкәттә, әгәр шулай әйтергә момкин булса, кешеләр белән аралашам, нindидер яна нәрсәләр беләм. Әлбәттә, мина да, Рамильгә дә башта кыенрак булды. Ләкин ярдәм иттеләр. Ул вакытта безнен сату буенча менеджер Руслан Хәйретдинов иде: ул минем остазым булды. Кибет хужасы Роберт Ринат улы Грошев та кvп нәрсәгә ойрәтә алды. Менә шулай әкренләп эш алга китте, сатулар яхшырды. Шулай, рәсемдәге менеджер Р.Б.Курмакаев һәм сатучы О.В.Даньшина кирәкле товарны жибәреп кенә калмыйча, сатып алучы Рамиль Курмакаевка эшлекле кинәш тә бирәләр.

Наилә НАСЫРОВА